| | |
|---|---|
| **ГЛАВА БОЛЬШЕРУСАКОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ОЛЫ УРСАК АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ** |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 елның 10 ноябрь Олы Урсак авылы № 3

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы
Олы Урсак авыл җирлегенең Кече Урсак авылында
гражданнарның үзара салым акчаларын
кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе
буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

06.10.2003 ел, № 131-ФЗ «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарәтурында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан РеспубликасыЗаконының 35 статьясына, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Олы Урсак авыл җирлеге Уставының 22 статьясына туры китереп КАРАР КЫЛА:

1.2023 елның 24 ноябрендә 11 сәгать 00 минутка Кече Урсак авыл клубы бинасында Кече Урсакавылы, Усманов урамы, 46 нчы йорт адресы буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Олы Урсак авыл җирлегенең Кече Урсак авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены билгеләргә.

2.Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

"2024 елда Татарстан Республикасы муниципаль районының Кече Урсак авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм даими яшәүче балигъ булган һәр кешедән 500(Биш йөз)сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерүгә җибәрүгә килешәсезме?

торак пункт территориясен төзекләндерүне оештыру:
авыл җирлеге торак пункты территориясен тоту
- материаллар сатып алып урам яктыртуын ремонтлау;
- авыл җирлеге территорияләрен һәм санкцияләнмәгән чүплекләрне чистарту;

торак пункт чикләрендә халыкны су белән тәэмин итүне оештыру:
- материаллар сатып алып суүткәргеч челтәрләрен ремонтлау;

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Олы Русак авыл җирлеге башкарма комитетына җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итүгә акча җибәрергә рөхсәт итәргә.

« ӨЧЕН» «КАРШЫ»

3.Әлеге карарны Олы Урсак авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән игълан итәргә һәм «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» бастырып чыгарырга http://pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Олы Урсак авыл җирлегенең рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге ка ул басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районы
Олы Урсак авыл җирлеге башлыгы Зиннәтуллин Г.А.